# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Сабай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

05.11.2025 №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Тимершык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына таянып 2025 елның 05 ноябренда узган гражданнар җыенында «2026 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Сабай торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Сабай торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сабай торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау - грунт эшкәртү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл кырыен төзү, су үткәрү торбаларын урнаштыру, эшләр өчен шартнамә буенча түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 25 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 23 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 23 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Сабай торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.
2. «2026 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Сабай торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Сабай торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сабай торак пункты

чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау - грунт эшкәртү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл кырыен төзү, су үткәрү торбаларын урнаштыру, эшләр өчен шартнамә буенча түләү) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Тимершык авыл
җирлеге Башлыгы

А.Х. Хаҗиев